**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Микулино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Микулино авылы № 22 16.04. 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2014 елның 14.11. 122номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2015 елның 17 августындагы 146 номерлы, 2015 елның 22 октябрендәге 12 номерлы, 2018 елның 24 апрелендәге 94 номерлы, 2018 елның 13 ноябрендәге 116 номерлы, 2018 елның 21 декабрендәге 116 номерлы, 2019 елның 25июньдәге 141 номерлы карарлар редакциясендә)

"Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 23 декабрендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Микулино авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2014 елның 14.11. 122 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (2015 елның 17 августындагы 146 номерлы, 2015 елның 22 октябрендәге 12 номерлы, 2018 елның 24 апрелендәге 94 номерлы, 2018 елның 13 ноябрендәге 116 номерлы, 2018 елның 21 декабрендәге 122 номерлы, 2019 елның 25июньдәге 141 номерлы карарлар редакциясендә) 3.2 пунктындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым органына салым ташламасы бирү турында гариза бирмәгән яисә салым ташламасын кулланудан баш тарту турында хәбәр итмәгән очракта, салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексы һәм салым түләүченең салым ташламасына хокукы барлыкка килгән салым чорыннан башлап салым органы тарафыннан алынган белешмәләр нигезендә бирелә."

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай

муниципаль районының Интернет- мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырырга: http://aznakayevo.tatar.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.А.Такиулин